**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге**

**КАРАР**
**02.11.2023 ел**

**КАРАР**
**№87**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының 2022 елның 25 ноябрендәге 63 номерлы Иске Имән авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең 4.1 пунктын төшереп калдырырга;

2) 3.6.1 пунктының «й» пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7.2 пунктындагы «д» пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында 3.11.10 бүлегендә «(тимер юл)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җир кишәрлекләре хокукы бирүчеләр үзләре милкендәге, биләгән яисә файдаланган җир кишәрлекләреннән Сосновский борщевикын алу буенча чаралар уздырырга тиеш, ә Сосновский борщевикын җир кишәрлекләреннән һәм җирләрдән алып ташлау чараларын, аларга дәүләт милке чикләнмәгән килеш, җирле үзидарә органнарын гамәлгә ашыра. Сосновский борщевикын алу чаралары күрсәтелгән ысулларның берсе яисә комбинациясе юлы белән уздырыла:

- химик яктан - гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар белән үсү чыганакларын сиптерү;

- механик яктан - чаптыру, коры үсемлекләрне җыю, тамыр системасын казып алу;

- агротехник яктан - туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.

6) 4.2.7 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга:

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова